УДК 314.7

*Я.М. Дәүләтшина,*
*Л.К. Мөхәммәтҗанова,*
*Р.Р. Хизбуллина*

# СӘЛӘТЛЕ ЯШЬЛӘР ҺӘМ МИГРАЦИЯ
## *(эмпирик тикшеренү нәтиҗәләре)*

Талантливая молодежь – это молодые люди, имеющие способности, высокую степень одаренности. Необходимо создать условия для успешной социализации и эффективной самореализации талантливой молодежи, детей. Целью данной статьи является представление результатов авторского исследования по определению основных направлений и причин потенциальной миграции талантливой молодежи Республики Татарстан. Реализация исследовательских задач была достигнута посредством методологического анализа и эмпирической проверки особенностей и причин миграции талантливой молодежи. Использованы данные авторского опроса, сравнительный анализ смежных исследований талантливой молодежи Республики Татарстан. Результаты исследования демонстрируют наличие заинтересованности молодых талантливых людей в поиске работы как в рамках родного региона, так и за его пределами. Основные причины миграции заключаются в поисках более интересных и современных программ обучения, привлекательной заработной платы, возможностей саморазвития. Ограничением миграционных потоков молодежи выступают в первую очередь психологические причины, наличие родственных связей, наличие жилья.

**Ключевые слова:** талантливая молодежь, миграция, молодежь, трудоустройство, социологическое исследование, талант

Һәр дәүләтнең миграция сәясәте беренче чиратта саннарга таянырга тиеш, чөнки ничә кеше күчеп китүен белми торып миграциянең максатын, юнәлешләрен, миграция агымын көйләү буенча эш күләмен, кирәкле чыгымнарны дәлилләп һәм әлеге адымнар нинди нәтиҗәгә китерүен белеп булмый.

Хәзер Россиядә, Татарстан Республикасында балалар һәм яшүсмерләрнең интеллектуаль-иҗади мөмкинлекләрен ачуга шактый игътибар бирелә. Сәләтле яшьләргә дәүләт тарафыннан ярдәм күрсәтү буенча норматив актлар, максатчан программалар да эшләп килә, сәләтле балаларны, яшьләрне барлау, яклау һәм аларның сәләтләрен тагы да үстерүгә юнәлдерелгән төрле чаралар, конкурслар уздырыла.

Дәүләт инновацион яктан уңышлы үссен өчен сәләтле яшьләр һәм белгечләр кирәк. Татарстан Республикасында сәләтле яшьләрнең күп булуы әлеге мәсьәләнең актуаль булуын һәм алар белән эшләүне яхшырту кирәклеген күрсәтә. Дәүләт, әти-әниләр һәм укытучылар сәләтле балалар һәм яшьләрнең аерым ихтыяҗларын исәпкә

алып, алар белән эшләүнең нечкәлекләрен белергә тиеш

Л. Гудков, Б. Дубин, Н. Зоркая, И. Воробьева, А. Кологривов, В. Сарксян, Г. Кошарная, Н. Корж, Е. Данилова, Е. Щанина һәм башка галимнәрнең теоретик һәм методик хезмәтләре яшьләр социаль-демографик төркеменең тормыш юлында килеп туган проблемаларын өйрәнүгә багышланган.

Татарстан Республикасы хөкүмәте һәм РГНФ тарафыннан хупланган «Татарстан Республикасындагы сәләтле яшьләрнең проблемалары һәм үсеш перспективасы» (№ 16-13-16008) фәнни проекты кысаларында социологик тикшеренү үткәрелде һәм сәләтле яшьләрнең төбәктән күчеп китү сәбәпләре һәм китү юнәлешләре тикшерелде.

Социологик тикшеренү 14–35 яшьтәгеләр арасында (n=600 кеше) репрезентатив сайлау ысулы белән Татарстан Республикасының дүрт муниципаль районында үткәрелде. Тикшеренү төрле конкурсларда, олимпиадаларда, конференцияләрдә һәм башка төрле бәйгеләрдә җиңүче, лауреат булган яшьләр арасында уздырылды. Сәләтле яшьләрнең фикерен белү анкета сорауларына җавап алу методы һәм Интернет челтәре ярдәмендә алып барылды.

Респондентларның фикерен анализлау сәләтле яшьләрне бүген борчыган түбәндәгене мәсьәләләрне күрсәтте (1 нче рәсем):

1. Дөнья вазгыяте – 32%
2. Шәхси проблемалар – 39%
3. Эшсезлек – 17%
4. Карьера үсеше – 22%
5. Шәхси үсеш өчен мөмкинлек – 28%
6. Өстенлекле югары уку йортына керү – 16%
7. Белгечлек буенча эш эзләү – 31%
8. Фәнни-тикшеренү проектларын финанслау проблемасы – 3%




1 нче рәс. Сәләтле яшьләрне бүген борчыган мәсьәләләр, сораштырылган респондентларның % лардагы чагылышы

9. Торак сатып алуга бәйле авырлыклар – 22%

10. Фәнни конференцияләрдә/семинарларда/симпозиумнарда катнашу өчен финанс табу проблемасы – 3%

11. Башкалар – 4%.

Тикшеренү процессында хәзерге яшьләрне аеруча белгечлек буенча эш табу, шәхси үсеш өчен мөмкинлек һәм карьера буенча күтәрелү проблемалары борчуы күзәтелгәнгә күрә, аларга теләгән белгечлек/һөнәр буенча Татарстанда эшкә урнашу перспективасына кагылышлы сорау бирелде. Сораштырылганнарның яртысыннан артыгы (58% ы), теләгән белгечлек/һөнәр буенча Татарстанда урнаша алам, дип нык ышаныч белдерә, 9% ы Татарстанда һөнәр буенча эш табу авыр, дип уйлый, яшьләрнең 18% ы, андый эш булып та анда урнашу авыр, ди, тагын 18% ы андый эш булып та анда урнашып буламы-юкмы икәнлеген белмиләр. Респондентларның 5% ы үз вариант җавапларын тәкъдим иттеләр (2 нче рәсем).

Алынган мәгълүматлар буенча, сәләтле яшьләрнең 54% Татарстан Республикасының башкаласы – Казанда урнашкан югары уку йортларына өстенлек бирә. 12 % Татарстанның башка шәһәрләрендә урнашкан уку йортларын сайлый һәм калган җаваплар Мәскәү, Санкт-Петербург һәм чит ил югары уку йортларына туры килә (3 нче рәсем).

Респондентларның җаваплары нисбәтеннән, аларның ни сәбәпле башка регионнарда урнашкан уку йортларын сайлавы кызыксындыра. Түбәндә респондентларның Татарстаннан читтә булган югары уку йортларына өстенлек бирүенең сәбәпләрен күрсәтүче җаваплары китерелә (4 нче рәсем):

1. Заманчарак һәм кызыклырак укыту программалары – 31%.

2. Әлеге югары уку йортын тәмамлагач эшкә урнашу мөмкинлеге зур – 27%.

3. Анда укуы абруйлырак, мәртәбәлерәк – 20%.

4. Башка вариантлар – 10%.

Хезмәт миграциясенең төп сәбәбе итеп, югары хезмәт хакын санаган респондетлар – 29% ны, карьера буенча күтәрелергә мөмкинлек булуын санаучылар – 21% ны һәм кызыклы эш кысаларында үзеңнең проект, идеяләреңне тормышка ашыра алу мөмкинлеге булуын санаучылар 17% ны тәшкир итә. Сораштырылылган яшьләрнең башка җаваплары 5 нче рәсемдә китерелгән.

Хезмәт миграциясен үзләре өчен мөмкин түгел, дип санаучы һәм Татарстан Республикасында эшкә калырга теләүче респондентлар түбәндәге сәбәпләрне китерәләр: 33% ы – «монда минем туганнарым, дусларым бар», 18% ы – яшәү өчен торак бар (6 нчы рәсем).

Сораштырылган яшьләрнең 44% ы «яхшы перспектива, һөнәри үсеш өчен мөмкинлекләр бар» дип исәпли, шуңа күрә Татарстанда эшкә урнашу перспективасына югары бәя бирә, әмма респондентларның 27% ы хезмәт хакының җитәрлек куләмдә булмавына борчылуын белдерә һәм шәхси үсеш буенча кайбер чикләүләр бар дип саный (7 нче, 8 нче рәсемнәр).




2 нче рәс. Яшьләрнең теләгән белгечлеге/һөнәре буенча Татарстанда эшкә урнашу мөмкинлеге (сораштырылган респондентларның % лардагы чагылышы)




3 нче рәс. Респондентларның «Кайда урнашкан уку йортлары-на өстенлек бирдегез/бирәчәксез» дигән сорауга җавапларның бүленеше (сораштырылган респондентларның % лардагы чагылышы)




4 нче рәс. Башка регионнарда урнашкан югары уку йортларын сайлау сәбәпләре (сораштырылган респондентларның % лардагы чагылышы)




5 нче рәс. Россиянең башка шәһәрләренә яки чит илләргә күчеп китүнең сәбәпләре (сораштырылган респондентларның % лардагы чагылышы)




6 нче рәс. Башка шәһәрләргә, чит илләргә китмәүнең сәбәпләре (сораштырылган респондентларның % лардагы чагылышы)




7 нче рәс. Татарстанда эшләү перспективасын бәяләү (сораштырылган респондентларның % лардагы чагылышы)




8 нче рәс. Татарстанда һөнәри үсеш өчен мөмкинлекләр чикләнү сәбәпләре (сораштырылган респондентларның % лардагы чагылышы)

Автор тикшеренүе материаллары, сораштыру нәтиҗәләре 2013 елда Татарстан Республикасындагы яшьләрнең тормыш концепциясе темасы буенча социологик тикшеренү үткәргән Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе белгечләре мәгълүматлары белән аваздаш. Яшьләр уку стратегиясе формалаштырганда белем бирү сыйфаты турында гына уйламый, ә эти-әниләренең фикеренә дә карый һәм өйгә якынрак уку йортларын сайлый. Төрле конкурсларда, олимпиадаларда, конференцияләрдә һәм башка бәйгеләрдә җиңүче, лауреат булган яшьләрнең күбесе үзенең укуын Татарстаннан читтә дәвам итәргә тели, сәбәбе – индивидуаль карьерада шәхси үсеш мөмкинлеге булуы [Тюрин].

Тикшеренү нәтиҗәләре буенча шуны әйтергә була: сәләтле яшьләр туган төбәгендә яисә аннан читтә үзенә эш табуга кызыксыну барлыгын күрсәтә. Миграциянең төп сәбәбе булып тагын да кызыклырак һәм заманчарак белем бирү программасы эзләү, югары хезмәт хакы, шәхси үсеш өчен мөмкинлек барлыгы тора. Миграцияне туктатучы фактор булып беренче чиратта психологик сәбәпләр тора; монда туганлык мөнәсәбәтләре яки торак мәсьәләсе дә җитди роль уйный.

Эмпирик тикшеренү кысаларында ачыкланганча, сәләтле яшьләрнең миграциясе белән бәйле проблемаларны хәл итү өчен регионда яшьләр өчен уңай социаль шартлар тудыру һәм үз-үзләренең ачу мөмкинлеге бирү, яшьләрнең хезмәт потенциалын сыйфатлы үстерү, аны дәүләт инновацион үсешендә актив файдалану зарур.

Россия Федерациясенең әйдәп баручы регионы буларак Татарстанда сәләтле яшьләрнең шәхси үсеше өчен тормышның төрле өлкәләрендә шартлар тудырылган. Татарстан Республикасының бу өлкәдәге өстенлеген тагын да арттыру сәләтле балалар һәм яшьләр өчен даими рәвештә интеллектуаль, иҗади, спорт чаралары уздыру һәм бизнес-элита формалаштыру белән бәйле.

**Әдәбият**

*Воробьева И., Кологривов А.* Что им дома не сидится // Прямые инвестиции. 2011. № 8 (112). С. 12–16.

*Гудков Л.Д., Дубин Б.В., Зоркая Н.А.* Молодежь России. М.: Московская школа политических исследований, 2011. 96 с.

*Сарксян В.Б.* Пермский край: опыт противодействия интеллектуальной миграции молодежи // Российское предпринимательство. 2012. № 17 (215). С. 44–50.

*Кошарная Г.Б., Корж Н.В.* Ценностные предпочтения студенческой молодежи в сфере труда // Известия высших учебных заведений. поволжский регион. Общественные науки. 2010. № 2. С. 64–73.

*Данилова Е.А., Щанина Е.В.* Молодежь в региональном социуме: теоретический аспект // Известия высших учебных заведений. Поволжский регион. Общественные науки. 2010. № 1. С. 62–69.

*Тюрин А.* Татарстан станет самым привлекательным регионом для талантливой молодежи. URL: https://kazanfirst.ru/article/227463

***Дәүләтшина Язгөлем Мөбәракша кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*КДЭУның чит телләр кафедрасы доценты,*
*e-mail: yazgul_ahmetova@mail.ru*

***Мөхәммәтҗанова Лилия Касыйм кызы,***
*биология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФАнең фәнни-оештыру бүлеге баш белгече,*
*e-mail: muhametzyanoval@mail.ru*

***Хизбуллина Радмила Радик кызы,***
*социология фәннәре кандидаты,*
*КДЭУның сәясәт һәм хокук социологиясе*
*кафедрасы доценты,*
*e-mail: mine_post@inbox.ru*